## Лилия Мәхмүтова: «Киләчәгемне беләсем килми – куркам»

Кирәк вакытта чабып барган атны туктатучы, әкирәгендә ир куенында йомшак песи кебек назлана белүче хатын-кызлар бар. Тинчурин театрында эшләүче Татарстанның халык артисты Лилия Мәхмүтова шундыйлардан. Танылган артистлар Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовларның кызы. Чирек гасыр гомерен театр сәнгатенә багышлаган ханымның хис-кичерешләре, киләчәккә өмет-хыяллары, үкенечләре турында сөйләшәбез.

5 БИТ

## Дубайның татар кызлары

Үзләре бик сиздермәсәләр дә, туган илләрен сагынулары кызларның күзләрендә. Алар монда дөньяның җәннәт кебек илендә яшәп ятсалар да, күңелләре туган илгә тоташкан. Гарәп Әмирлегендә 100 ел торсаң да, бу илнеке була алмыйсың. Илнең үз халкы файдалана торган ташламалар да, фатирлар да читтән килгәннәр өчен түгел монда.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

**Сишәмбе** | 7.03.2017 | №23 (5785)

**www.shahrikazan.com**

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# ГҮЗӘЛЛӘРДӘН ГҮЗӘЛЕ

**Бар яктан да үрнәк, фән, эшмәкәрлек өлкәсендә уңышларга ирешкән ел лидерлары кичә Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында җыелды. Биредә «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашыннан» республика бәйгесенә йомгак ясалды.**

Хатын-кызны төрле тармакта очратырга була, бизнес вәкиле дә ул, җәмәгать эшлеклесе дә. Ничек кенә булмасын, хатын-кыз ул – гаилә нигезе. Тантанада иң дулкынландыргыч мизгел Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең «Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңүчеләрне бүләкләве булгандыр.

Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты исеменнән барлык гүзәл затларны Халыкара хатын-кызлар көне белән котлады, аларга сабырлыгы, тырышлыгы, матурлыгы, ягымлылыгы өчен рәхмәтен белдерде.

– Бу чара хатын-кызлар белән очрашу гына түгел. «Татарстан хатын-кызлары» оешмасы барлыкка килүгә 20 ел тулу уңаеннан оештырылган бәйрәм дә. Теләсә кайсы заманда да, бернигә карамастан, бу – Әниләр бәйрәме. Әниләр – безнең бөтен барлыгыбыз. Әнидән дә изгерәк, кадерлерәк кеше юк. Без әниләребезне яратабыз, бәялибез, аларны хәтердә саклыйбыз. Әниләр безнең өчен мөмкин булмаганны да эшлиләр. Ничек инде моны бәяләмәскә мөмкин? Әнигә карата хөрмәт, ярату гомер буена озата килә, – диде Минтимер Шәймиев.

«Хатын-кыз – ана» исеменә Чаллыдан Светлана МуллануроBа, Түбән Камадан Дарья Хуҗина һәм Саба районы Югары Симет авылыннан Рушания Шамилова лаек дип табылды. Рушания апа 81 яшендә булса да, сөбханалла, бик җитез, күзеннән нур бөркелә. Ул – авылның абыстае. Рушания апа Симеткә килен булып төшкән. Ире Кавыйл абыйның беренче хатыныннан ятим калган биш баласын үзенекедәй итеп кабул иткән. Шамиловлар гаиләсендә тагын ике бала туа. Тик тигезлектә яшәргә генә насыйп булмый, биш ел парлап гомер иткәннән соң, Кавыйл абый кинәт гүр иясе була. Җиде баланы Рушания апа ялгызы үстерә. Гомер буе ул «Көнкүреш йортында» хезмәт итә. Пенсиягә чыккач та, аның янынан кешенең өзелгәне юк. Һәркем өчен ул – киңәшче, хөрмәткә лаек кеше. Бүген Рушания апа улы Айдар, килене Ләйсән тәрбиясендә яши, оныклары өчен яраткан дәү әни дә ул.

20 еллык тарихы булган бәйгегә быел 45 районнан барлыгы 700дән артык гариза кабул ителгән. Жюри ун юнәлеш буенча барлыгы 19 җиңүчене билгеләде.

«Хатын-кыз – мәдәният һәм рухилык» номинациясендә коллегабыз – «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова җиңү яулады. Аңа һәм «Хатын-кыз – Ел үрнәге» номинациясендә җиңүчеләргә бүләкне «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов тапшырды.

→ Ахыры 3нче биттә.

# Татарстан тәҗрибәсен өйрәнәләр

**Россиядә быел иҗтимагый мохитне, ягъни паркларны һәм скверларны төзекләндерү буенча федераль программа башлана. Республиканың шушы юнәлештәге тәҗрибәсен өйрәнер өчен, кичә Казанга илебезнең барлык төбәкләреннән 600гә якын кеше килде.**

**Дамир БӘДРИЕВ**

«Уңайлы шәһәр мохите булдыру» I Бөтенроссия семинарында катнашучыларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде.

– Без иҗтимагый мохитне төзекләндерү буенча республика программасын инде ике ел элек үк башладык. Республикада 189 парк һәм сквер яңартылды. Иҗтимагый мохитне төзекләндерү эшләрендә төрле тармаклар катнаша: яшелләндерүчеләр, төзүчеләр, электр яктырткычлары куючылар, кече архитектура сыннары урнаштыручылар, – дип таныштырды Рөстәм Миңнеханов. – Иҗтимагый мохит ул җәмәгатьчелекнең хакимияткә карата мөнәсәбәтен дә билгели. Парк юк, өлкәннәргә ял итү өчен җыелышып утырыр урын юк икән, әлбәттә инде, канәгатьсезлек хисе туа. Яшел зоналарны төзекләндерү буенча программада быелга исәпләнелгән эшләребезнең дә колачы зур. Халыкның да иҗтимагый мохитне проектлауда фикер-тәкъдимнәре белән катнашуы кирәк.

– Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин иҗтимагый мохитне төзекләндерү бурычы куйды. Әлеге бурычны гамәлгә ашыруда Татарстан Республикасының тәҗрибәсен өйрәнү мөһим, – диде Россиянең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Михаил Мень. – Балалар, киләчәк буыннар кайда уйнар? Иҗтимагый мохитне төзекләндерү – киләчәкне кайгырту ул. Кайгырту тойган кеше үзе дә игътибарлы була. Ишегалларын төзекләндерүдә катнашкан яисә шимбә өмәләренә чыккан кеше корылмаларга карата сакчыл мөнәсәбәт күрсәтә. Кеше капиталы – иң зур байлык. Заманча эш урыннары булдыру белән беррәттән уңайлы мохит тә тудыру зарур.

Автор фотосы

Михаил Мень әйткәнчә, Россиядә 12 145 муниципаль берәмлек исәпләнә. Бер мең кеше яши торган торак пункт та иҗтимагый мохитне төзекләндерү буенча Россиякүләм программада катнаша ала. Быелгы чараларга федераль бюджетта 20 миллиард сум тәгаенләнгән.

– Хәзер тиз арада быелга планнарны барларга кирәк. Шәһәр халкы ишегалларын төзекләндергәндә беренче чиратта нәрсәләр күрергә теләвен әйтсен, – диде Михаил Мень. – Әлбәттә, төзекләндерүләрне бер елда гына башкарып чыгып булмаячак. Иҗтимагый мохитне төзекләндерү максатында бишьеллык программа әзерләнәчәк.

«Бердәм Россия» сәяси партиясе Генераль советы секретаре урынбасары Ольга Баталина да: «Иҗтимагый мохитне төзекләндерүдә Татарстанның тәҗрибәсе зур, уңышлары искиткеч», – дип югары бәяләде.

– «Бердәм Россия» партиясе иҗтимагый мохитне төзекләндерү буенча әле 2011 елда ук башлангыч белән чыкты. Миллионлы шәһәрләрдә скверларны төзекләндерүгә федераль бюджеттан билгеле бер күләмдә финанс чыганаклары күчерүгә ирешелде, – диде Ольга Баталина.

«Бердәм Россия» сәяси партиясе үзе дә 30 мең кеше яшәүче торак пунктларда иҗтимагый мохитне төзекләндерү буенча быелгы чараларга 500 миллион сум ярдәм фонды булдырган.

– Шәһәрләрдә уңайлы мохит тудыру буенча тагын бер махсус проект башладык. «Бердәм Россия» сәяси партиясенең төбәк бүлекләре халыктан ишегалларын төзекләндерү буенча гариза-мөрәҗәгатьләр туплый. Элек хакимият органнары төзекләндерү исемлегенә ишегалларын сайлап ала иде. Хәзер күп фатирлы йортларда яшәүчеләр гомум җыелыш үткәреп, ишегалдын төзекләндерү турында үзләре дә «Бердәм Россия»нең төбәк бүлекләренә мөрәҗәгать җибәрә ала, – диде Ольга Баталина.

Башкалада иҗтимагый мохитне төзекләндерү «100 сквер» проекты белән старт алган иде. Казан мэры Илсур Метшин әйткәнчә, паркларны һәм скверларны төзекләндерү буенча Татарстан Президенты башлангычындагы программа эшләрне колачлы рәвештә үткәрү мөмкинлеге тудырган. Биш ел эчендә шәһәрнең 49 паркы һәм скверы яңартылды, әлеге эшләрне башкарырга ике миллиард сум тотылган. Предприятиеләр белән эшкуарлар да ярдәм күрсәтә. Казандагы 25 парк һәм скверның иганәчеләр советы бар. Хәзер башкалада парклар һәм скверлар саны – 137, ә яшел зона 354 гектар. Быел да паркларны һәм скверларны төзекләндерү дәвам итәчәк. Кабан күле, Аккош күле шулар арасындагы зур проектлар булып тора.

# «Бу хәлдән чыгуның ике юлы бар»

**3 март көнне Үзәк банк карары нигезендә «Татфондбанк», «Интехбанк» һәм «Анкор Банк»ның лицензияләре алынуы билгеле булды. Бу уңайдан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ашыгыч киңәшмә уздырды. Ул, банк активлары читкә чыгарылмаска тиеш, дигән бурыч куйды.**

Әлеге чара банкның зыян күргән клиентларына түләүләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Шулай ук банк тармагында кризис килеп чыгуга катнашы булган бөтен затларны җаваплылыкка тартырга дип тә ассызыклады Президент. Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан журналистлар белән очрашуда да ул бу теманы игътибарсыз калдырмады.

– «ТФБ Финанс» – «Татфондбанк» эчендәге структура. 1,7-1,8 мең кеше үз кертемнәрен башка бүлекләргә күчергән. Алар дәүләт тарафыннан иминиятләштерелмәгән. Без кешеләрнең кертемнәрен кире рәсмиләштергәнен белмәдек. Бүген барлык хокук саклау системасы да менеджерларның гаебен ачыкларга тырыша. Кулга алынучылар бар, тагын булачактыр, – дигән Президент.

Гаепләләргә килгәндә, «Аеруча зур күләмдә акча үзләштерү» маддәсе буенча инде биш кеше кулга алынды. Аларның барысы да «ТФБ Финанс» («Татфондбанк»ның бүлендеге) инвестиция компаниясеннән барлыгы 90 миллион сум акча урлауда гаепләнә. «Татфондбанк»ның элеккеге җитәкчесе 52 яшьлек Роберт Мусин исә 16 апрельгә кадәр сак астында булачак.

Кичә Татарстанның Сәүдә-сәнәгать палатасында премьер-министр Илдар Халиков «Татфондбанк» һәм «Интехбанк»тан зыян күргән кертемчеләрнең инициатив төркеме белән очрашты. Премьер-министр сүзләренчә, бу хәлдән чыгуның ике юлы бар: Үзәк Банк карарын кире алдыру яисә банкларның банкротлык процедурасын башлау. Илдар Халиков Татарстан Хөкүмәтенең «ТФБ Финанс» клиентларына банк кертемчеләре белән тигез хокук бирә торган юридик мөмкинлекләр эзләвен дә әйтте. Бу алданган «ТФБ Финанс» кертемчеләре Иминият кертемнәре агентлыгы аша акчаларын кайтара алсын өчен кирәк, дип хәбәр итә «Татар-информ».

Татарстанның Икътисад министрлыгы матбугат үзәге җитәкчесе Инсар Сәгыйтов аңлатуынча, кредит оешмалары банк операцияләрен башкару хокукыннан мәхрүм булуына карамастан, кредиторларның таләпләрен игътибарсыз калдырмаячаклар. Килешү нигезендә клиентлары гомеренә, сәламәтлегенә зыян китергән очракта банк җавап тота, шуңа да физик затларның мәнфәгатьләрен беренче чиратта канәгатьләндерәчәкләр. Икенче чиратта хезмәт килешүе нигезендә банк эшчеләренең хезмәт хаклары, пособиеләре түләнә. Калган зыян күрүчеләрнең таләпләре өченче чиратта канәгатьләндереләчәк.

Россия Үзәк Банкы Татарстан җитәкчелеге белән берлектә «Татфондбанк»ка бәйле хәлне чишүдә актив эш алып бара – алар кертемчеләрне, шул исәптән юридик затларны да яклау юлларын эзли. Белгечләр, Татарстан банклары белән бәйле хәлләр республиканың икътисадына зур йогынты ясамаячак, дип фаразлый. Россия Банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина да «Россия 24» телеканалына биргән әңгәмәсендә, «банк секторы күзлегеннән Татарстанның банк системасында вазгыять тотрыклы» дип ышандыра. Ничек кенә булмасын, банклар белән вазгыятьтә таякның юан башы эшмәкәрләргә төшә. Күпләргә барысын да яңадан башларга туры киләчәк.

Татарстанның бизнес-омбудсмены Тимур Ногманов, закон нигезендә, оешма бөлгенлеккә төшкән очракта, кредиторлар компенсация алырга хокуклы, ди. Моның өчен Үзәк банк тарафыннан лицензияләре алынган «Татфондбанк», «Интехбанк», «Анкор Банк»ның эшмәкәр клиентларына кредиторлар реестрына әләгү өчен, Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгына гаризалар тапшырырга тиеш. Гариза тапшыру тәртибен ул үзенең Инстаграм битендә дә аңлатып язган.

«Татфондбанк»ны киләчәктә нәрсә көтә, лицензиясе алынган банкларның клиентларына нәрсә эшләргә? Бу хакта тулырак язманы газетабызның киләсе санында укый аласыз.

*Кертемнәрне кайтару турында тулырак мәгълүматны Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгының «кайнар элемтә» номеры* ***(8-800-200-08-05)*** *аша, шулай ук агентлыкның «Иминият кертемнәре/Иминият очраклары»* ***(www.asv.org.ru)****. бүлекчәсендә дә укырга була.*

# Ил күләмендә үрнәк

Автор фотосы

**Эш-гамәлләрнең колачы, әһәмияте, нәтиҗәсе чагыштырып караганда яхшырак беленә.**

– Казандагы «Уңайлы торак» идарәче компаниясе – торак-коммуналь хуҗалык реформасында Россия күләмендә әйдаман, – диде «Милли торак конгрессы» коммерциячел булмаган автоном предприятие директоры Татьяна Вепрецкая. – Бередә торак фондны карау, энергиягә сакчыллык, яңа технологияләрне кулланышка кертү, торак милекчеләре белән эшләү кебек кайсы гына юнәлешне алсаң да, уңай нәтиҗәләргә ирешелә. Шунлыктан без «Уңайлы торак» идарәче компаниясендә ике ел саен бөтенроссия семинар киңәшмәләре үткәрәбез. Файдасы бар: төрле төбәкләрдән килгән идарәче компанияләр җитәкчеләре, инженерлары «Уңайлы торак» кулланучы технологияләрне үзләрендә дә булдыралар.

Яңа Савин районының «Уңайлы торак» идарәче компаниясендә «Торак-коммуналь хуҗалык комплексында нәтиҗәле идарә итү алымнары» темасына янә Россия күләмендә семинар-киңәшмә узды.

– Монысында Россиянең 20 төбәгендәге идарәче компанияләрнең юристлары җыелды. «Уңайлы торак» идарәче компаниясендә документлар белән эшләү тәртибе шулай ук күпләр өчен үрнәк, – диде Татьяна Вепрецкая.

Казанда торак-коммуналь хезмәтләр өчен электрон рәвештә түләү мөмкинлеге, бердәм исәп-хисап үзәкләрендә электрон чират тәртибе, коммуналь хуҗалык белгечләренең һөнәри белемен камилләштерү үзәге эшчәнлеге семинар-киңәшмәдә катнашучыларда чын мәгънәсендә соклану тудырды.

– Торак-коммуналь тармакта һәр юнәлештә сакчыллыкка ирешергә тырышабыз. Безнең төп максат – халыкка уңайлы көнкүреш шартлары тудыру, – диде «Уңайлы торак» идарәче компаниясе генераль директоры Марат Нуриев семинар-киңәшмәдә ясаган чыгышында.

**Дамир БӘДРИЕВ.**

# Мәктәп үзе бер дәүләт

**Бүген һәр мәктәп үзе бер дәүләт кебек. Укучыларның министрлары, хәтта үз президентлары бар. Ләкин бу «дәүләтнең» президенты булу җиңелләрдән түгел. Конкурентлар вазифаңнан алып ташларга да күп сорап тормый.**

Бу көннәрдә Казанның 177нче лицеенда «С.О.К. Стань одной командой» бәйгесе кысаларында нәкъ менә шундый актив президентлар үз командаларын тәкъдим итте. Бәйгенең максаты – иң яхшы мәктәп үзидарәсен сайлау. Бәйгенең бу этабында җиңүчеләр Татарстан данын ил күләмендә яклаячак.

– Без ел әйләнәсендә дистәдән артык чара оештырырга тиеш. Узган елны, 150 кешелек хор белән, «Җиңү көне» җырын башкардык. Ел саен гимназия балын оештырабыз. Президент булу җиңелләрдән түгел. Сайлап алу турында биргән вәгъдәләреңне ел әйләнәсе үтәргә тиешсең, – дип таныштырды үз мәктәпләрендә барган эш белән Азнакай районы укучысы Камилә Гобәйдуллина.

177нче лицей үзидарәсе белән Россия мәгариф һәм фән министры статс-сәркатибе Павел Зенькович та таныште.

– Без бер ел элек хыялланган әйберне сезнең ярдәм белән тормышка ашырырга ирештек. «Россия студентлар хәрәкәте» активистлар рәте елдан-ел арта. Үзегезне мәктәптә министр, президент буларак сынап карау сезгә үсәргә, үз инициативагызны күрсәтергә зур мөмкинлек бирәчәк. Бүген мине ишек төбендә мәктәп президенты каршы алды. Бик җитди егет. Киләчәктә ул безне хакимиятнең башка коридорлары буйлап йөртер дип ышанам, – диде Павел Зенькович.

Исегезгә төшерәбез, «Россия мәктәп укучылары хәрәкәте»н Россия Президенты Владимир Путин тәкъдим итте. Әлеге хәрәкәткә республиканың 58 мәктәбе кушылган.

**Алисә САБИРОВА.**

# Гүзәлләрдән гүзәле

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

Бизнес леди хатын-кызларны, «Өченче буын героинясы» номинациясендә җиңү яулаган Әлмәт районы ветераннар Советы комиссиясе рәисе Ираида Коршунованы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Татьяна Ларионова тәбрикләде.

«Хатын-кыз – лидер», «Язмышым – һөнәрем», «Хатын-кыз – галимә» юнәлешендә җиңү яулаучыларга бүләкне Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова тапшырды. Бәйрәм азагында традиция буенча «Татарстан хатын-кызлары» төбәкара иҗтимагый оешмасының рәисе, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева «Ир-ат – мәрхәмәтле йөрәк» номинациясендә Татарстанның халык артисты («Әкият» дәүләт курчак театры) Александр Карпеевны, «Ир-ат – лидер» номинациясендә «Таттелеком» җәмгыятенең генераль директорын, Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллинны җиңүләре белән котлады.

Бәйрәмгә чакырылган 750ләп кунак арасындагы ханымнарның барысы да хөрмәткә лаеклылар. Әлки районының Яңа Әнҗерә авылыннан килгән Любовь Гобәйдуллина – алты бала анасы. Ул бәйгенең район турында җиңгән булган. Чуваш кызының саф татар телендә сөйләшүенә сокланырлык. Бөтенроссия татар гаиләләре фонды директоры Миләүшә Гайфуллина исә үзе дә ике ел элек «Хатын-кыз – лидер» номинациясендә җиңү яулаган булган. «Бүген дә чыгышларга сокланып, үрнәк хатын-кызларыбыз белән горурланып утырдым», – ди ул. Миләүшә ханым фикеренчә, мондый бәйгеләр хатын-кызлар һәм ир-егетләрнең җәмгыятьтәге дәрәҗәсен күтәрергә, үзеңнең сәләт һәм мөмкинлекләреңне, үрнәк хатын-кызның нинди булуын күрсәтергә ярдәм итә.

# Хәбәр ит тә акча эшлә

**Ялган аракы сатучыларга каршы көрәштә хәзер халык та актив катнаша. «Халык контроле» проекты кысаларында, законсыз алкоголь продукциясе сату турында һәркем хәбәр итә ала. Әгәр дә факт расланса, хәбәр итүче акчалата бүләкләнә.**

2017 елда Татарстан хөкүмәте, «Халык контроле»нә бу хакта хәбәр иткән кешеләрне кызыксындыру максатыннан, 2 миллион сум акча бүлеп биргән. Былтыргы белән чагыштырганда, бу сумма ике тапкырга арткан.

2016 елда ялган аракы турында халыктан кабул ителгән хәбәрләрнең 33 проценты дөреслеккә туры килгән. Дөрес мәгълүмат җиткергән кешеләргә барлыгы 303 мең сум күләмендә акча тапшырылган. Быел да халыкның активлыгы сизелә. Ике ай эчендә генә дә 257 шикаять кабул ителгән.

«Халык контроле» интернет проектына мөрәҗәгать итү өчен, башта дәүләт хезмәтләре порталында теркәлү мәҗбүри. Анда үзегезгә кирәкле категорияне сайлап, картада проблемалы урынны билгеләргә, төгәл адресны күрсәтергә кирәк. Хәбәрләрне «Сату кагыйдәләрен бозу», «Җәмәгать тынычлыгы», «Этил спирты, алкоголь яки составында спирт булган продукцияне законсыз рәвештә җитештерү, аның әйләнеше» дигән өч категория буенча юлларга мөмкин. Дәлил сыйфатында фотоматериаллар да кабул ителә. Контрафактлы исерткеч эчемлекләр сатылу очраклары турындагы хәбәр расланган очракта, дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүмат хуҗасына 1-3 мең сум күләмендә акча түли.

---

Татар дөньясы зур югалту кичерә. Халкыбызның затлы улы, милләтпәрвәр шәхес, туган җирен, туган авылын, үз милләтен зурлаган, башкалары хөрмәтләгән, гаиләсен, туганнарын, авылдашларын яраткан Гали авылы егете Расих Латыйпов бакыйлыкка күчте. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Самара өлкәсе Похвистнево районы татарларының «Туган тел» мәдәни-агарту иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, «Хәләл» җаваплылыгы чикләнгән оешмасы генераль директоры, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы, «Бөтенроссия татар авыллары» оешмасы рәисе урынбасары, җәмәгать эшлеклесе

**Расих Мөҗәһит улы ЛАТЫЙПОВ**ның

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Аллаһы Тәгалә барысына да сабырлык бирсен. Мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын.

# Дубайның татар кызлары

**Гарәп Әмирлегенә сәяхәтебез турында газетабызның быелгы 11нче санында язган идем инде. Тик без Дубайга турист булып кына түгел, кунак булып та бардык. Әллә шуңа бу сәяхәтебез башкаларыннан үзгә, җылырак һәм тәэсирлерәк булып истә калды.**

## ЗӨЛФИЯ

Кодачабыз Зөлфия туйга Дубайдан кайткан иде. Аннары җәй көне Казанда очраштык. Нәкъ менә аның гаиләсе белән кайтып-китеп йөрүе Дубайның барып җитә алмаслык җир түгеллеген искәртте бугай безгә. «Барасыбыз килә», – дигәч тә, «Килегез!» – дип, хәер-фатихасын бирде Зөлфия. Ул үзе дә балалары белән Казаннан кайткан гына иде әле. Ләкин алар Баку аша, ә без турыдан очтык Дубайга. Кызык инде, чактан гына бер самолетка туры килмәгәнбез.

Кайту белән, безне өйләренә кунакка чакырды кодача. Урамда йөреп әлсерәгән идек, декабрь аенда 31 градус эсселеккә күнекмәгән ич без. Унҗиденче каттагы фатирның зур тәрәзәләреннән Фарсы култыгының шәһәргә кергән каналындагы бай абзыйларның кыйммәтле яхталарына карап, Казан, Татарстан яңалыкларын сөйләшеп, чәйләп утырдык. Ире чит илдә командировкада, улы белән кызы мәктәптә укуда иде. Алар Дубайның диңгез буена урнашкан Дубай Марина районында биек йортта яшиләр. Шуңа да аңа безне якындагы пляжга озатып кую кыен булмады. Икенче тапкыр без Зөлфия белән (бу юлы ул кызын да алып килгән иде) кафеда сөйләшеп утырдык. Кызыннан мәктәп хәлләрен сораштым. Әңгәмәбезгә әнисе дә кушылды. Белем бирү системасы шулай ук бик үзенчәлекле икән биредә. Мәктәпкә нәниләр дүрт яшьтән керә. Баштарак дәресләр уен формасында үтә. Беренче сыйныфта укыткан укытучы икенче сыйныфта белем бирми инде. Ул шул беренчеләр буенча гына махсуслаша. Икенчеләрнеке дә шулай. Укытучының яраткан һәм яратмаган укучылары булмасын өчен бу шулай эшләнә, диделәр. Укытучылар гына түгел, укучылар да бер елдан соң параллель сыйныфның башкасына күчерелә. Монысы сыйныфта төрле төркемнәр булмасын өчен уйлап табылган ысул булып чыкты. Йөздән артык милләт баласы укыган мәктәптә башкача булмыйдыр инде. Ә болай безнең башка бик сыен бетми. Сыйныфташлар гомерлек дус була бит алар. Һәрхәлдә, элек бездә шулай иде. Балаларның белеме дә бездәге шикелле 5 балл белән генә түгел, ә 100 балл белән бәяләнә. Мәктәп укучылары ел саен имтихан тапшыралар, инглиз, гарәп, испан, француз телен өйрәнәләр. Онытылып бетмәсен дип, рус теленә дә, төрле түгәрәкләргә дә йөриләр. Иртән киткән балалар кичкә генә өйләренә кайтып җитә. Дубайда мәктәп автобусларын еш очратасың. Алар сары төстә һәм махсус юлдан баралар. Балаларның мәктәпләргә барып кайтуы шулай уңай хәл ителгән. Зөлфия әни булып кына эшли, хуҗабикә. Дубайга ирен озак вакытлы командировкага җибәргәч, күчеп килгәннәр. Аңарчы Себер якларында яшәгәннәр. Ире Әлмәттән, шунда Себердә танышканнар. Ике балалары бар: бер малай, бер кыз.

## АЙСЫЛУ

Күз алдыбызда үскән үзе чибәр, үзе тырыш, ике мәктәпне дә (берсе музыка мәктәбе) «бишле» билгеләренә генә тәмамлаган күрше кызы Айсылу да гаиләсе белән Дубайда яши. Беренче тапкыр 2012 елда Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация составында барган Айсылу Әмирлеккә. Аннары «Сәләт» лагеренда

танышкан беренче мәхәббәте Рамазанга кияүгә чыккан. Хәләл җефете, мәктәпне тәмамлагач, университетта укырга Әмирлеккә киткән булган. Ике йөрәкне бәйләүче мәхәббәт җепләре нык булгач, диңгезләр, чүлләр аша да, еллар аша да өзелмәгән.

Декрет ялына киткәнче, Айсылу Дубайда реклама агентлыгында эшләгән – инглиз телендә бит әле ул. Анысына гаҗәпләнерлек түгел инде: Казан дәүләт университетын тәмамлагач, «Алгарыш» программасы буенча инглиз телен Америкага барып өйрәнгән кыз бит ул! Шаккатарсың, татар кызлары беркайда да югалмыйлар: машина да йөртәләр, теттереп инглизчә һәм гарәпчә сөйләшәләр, чит илдә дип тормыйлар, балалар үстерәләр, аларга ана телебез – татар телен дә өйрәтәләр. Айсылуның Ибраһимына – яшь ярым. Кунакларның бик ерактан килгәнен сизенде бугай балакай, көне буе безнең белән машинада йөрсә дә, әнисенә комачаулап көйсезләнмәде.

Үзләре бик сиздермәсәләр дә, туган илләрен сагынулары кызларның күзләрендә. Алар монда дөньяның җәннәт кебек илендә яшәп ятсалар да, күңелләре туган илгә тоташкан. Гарәп Әмирлегендә 100 ел торсаң да, бу илнеке була алмыйсың. Илнең үз халкы файдалана торган ташламалар да, фатирлар да читтән килгәннәр өчен түгел монда. Кайчан да булса, бәлки тиздән туган якка кайтасыларын белеп, шуңа өметләнеп яшиләр алар. Ә туган ил мәрхәмәтле әни кебек: бер генә баласын да чит итми. Бигрәк тә Зөлфия, Айсылу кебек белемле кызларыбызны һәрчак кочак җәеп каршы алачак.

**Йолдыз ШӘРАПОВА.**

**ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ**

# Сездән башка без ник кирәк?

Авылга әнигә шалтыраттым. Беренче сорау гадәттәгечә: «Ничек хәлләрең, әни?» Инде 80не тутырып килүче әнидән гадәттәге җавап: «Әйбәт, улым». Менә шул «Әйбәт, улым»ны гел ишетеп торасы килә шул... Аннан авыл яңалыкларын тыңлыйм. Казаннан бик еракта бетеп барган туган авылымның хәлләрен беләм, кайтып урамнарда йөргәндәй булам.

Өйрәнелгән тәртипне бу юлы да бозмадык:

–Ничек хәлләрең, әни?

– Әйбәт, улым.

Ә аннан нидер үзгәрде...

Әни гадәттәгечә авыл хәлләренә күчмәде, ә җентекләп, минем тормыш белән кызыксынды. Кайда, ничек, кем белән, нигә?

– Бар да яхшы, әни. Бар да бар.

Юк, әнине мондый җавап кына канәгатьләндермәде, төпченде дә төпченде. Нәрсә эшлим, нәрсә ашадым, ашарга, яшәргә акчам бармы, өй җылымы... Сораулар бик күп булды. Җаваплар ананы бераз тынычландырды бугай, ул, ниндидер шатлыклы тонга күчеп:

– Гел шулай бәхетле бул, улым! – дип куйды. – Мин бит сине өч яшеңә кадәр: «Бәхете булсын!» – дип теләкләр теләп имездем, син бәхетле булырга тиеш, – диде әни, ничектер дулкынланып. Аннары ашыгыбрак сөйли башлады: – Беләсеңме, сине табарга больницага киткәндә, мәрхүм атаң: «Кыз булса, алып та кайтма», – дип калды. Безнең яктан без биш кыз бит, шуңа шулай әйткәндерме, белмим. Алай дисәң, әтиең апаңны өзелеп ярата. Соңгы көнгә кадәр гел киңәшләшеп тордылар, апаң– әтиеңне, әтиең апаңны кайгыртып торды. Ә менә сине нәкъ малай буларак көтте. И-и-и-и, сине тапкач, сөенгәннәрен күрсәң! Яшерен тормыйм инде, авыл белән бер атна эчтеләр. Еллары шундый иде бит. Мин дә шатландым, малай бит. Бәлки шуңа кадерледер син, улым. Үпкәләмәсеннәр, апаңнар өчен алай борчылмыйм, һәр иртәне сиңа дип атап теләк телим. Аерым телим. Бәхете булсын, юлын дошманнар кисмәсен, якыннары булсын дим. Бәхетле бул инде син, улым!

Әнинең бу сүзләреннән ничектер тетрәнеп киттем. Болай сөйләгәне юк иде. Нишләп алай? Сөйләшеп бетергәч тә бер тын уйланып яттым. Иң беренче, әлбәттә, мине бу җиргә малай итеп тапканы өчен, әнигә рәхмәт укыдым. Икенчедән, минем бар эшләремнең дә уңай баруы өчен дә әниемә рәхмәт әйттем.

Өченчедән...

Әни... Сөйгән ярлар китә, дуслар китә, иптәшләр китә. Әни гел минем янда. Иң авыр чакларымда да ул суза ярдәм кулын. Әни һәм бертуган апам, кызым. Тагын ярдәмгә килүчеләр бар. Аларын атап тормыйм – сүзе күп булыр, тик алары да хатын-кызлар! Бәрәч, бер уйласаң, минем бар яшәешем, бәхетем, уңышым хатын-кыз кулында икән бит! Эшләвем, яшәвем дә алар өчен икән! Бу турыда уйланганым юк иде әле. Хәер, миндә генә түгелдер мондый хәл. Хатын-кыз булмаса, бу җирдә ирләр нигә кирәк?

Бәйрәм белән сезне, безне яшәтүчеләр. Әниләр, апалар, сеңелләр, кызлар бәйрәме белән!

**Илфак ШИҺАПОВ.**

КУНАК БҮЛМӘСЕ

# Лилия Мәхмүтова:
# «Киләчәгемне беләсем килми – куркам»

**Кирәк вакытта чабып барган атны туктатучы, ә кирәгендә ир куенында йомшак песи кебек назлана белүче хатын-кызлар бар. Тинчурин театрында эшләүче Татарстанның халык артисты Лилия Мәхмүтова шундыйлардан. Танылган артистлар Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовларның кызы. Чирек гасыр гомерен театр сәнгатенә багышлаган ханымның хис-кичерешләре, киләчәккә өмет-хыяллары, үкенечләре турында сөйләшәбез.**

**Алисә САБИРОВА**

**– Сер түгел, артистларга төп рольләрдән тыш, икенчел пландагыларын да уйнарга туры килә. Сез 2012 елда Элла Васыловна роле өчен («Күрәсем килгән иде» спектакле) «Тантана» театраль премиясенә икенче пландагы хатын-кыз ролен иң яхшы башкаручы буларак тәкъдим ителгән идегез. Икенче планда уйнап, тамашачыга үз фикереңне җиткерү, образны ачып бирү кыенмы?**

– Мин рольләремне беркайчан да беренче, икенче планга бүлмим. Аны аерырга да кирәк түгел, чөнки икенче планда гына уйныйм, ул сыйфаты буенча начаррак булырга тиеш дигән әйбер юк. Мәсәлән, «Мәхәббәт чишмәсе» спектаклендә мин уйнаган Зәмзәмия төп роль түгел. Ләкин ул образ булмаса, бу спектакль алай күңелле булмас иде.

**– Иң яраткан, күңелегезгә хуш килгән роль дип кайсысын әйтер идегез?**

– Бер рольне дә уйланмыйча башкарып булмый. Театрга килгән чорда мин күбрәк лирик образлар башкара идем, тора-бара кискен характерлы үткен рольләр дә бирә башладылар. «Нәселдән күчкән» ролем дә бар. Ул – «Хуҗа Насретдин»да Гөлбану образы. Баштарак аны әни уйнады, Камал театрында әнинең сеңлесе Рузия апа башкарган иде. Соңгы куелышта миңа бирделәр. «Шаушулы көн, яки Фигароның өйләнүе» спектакле бик масштаблы иде. Ләкин аны озак уйнарга туры килмәде, ул вакытта авырлы идем. Хәзер бик яратып Зәмзәмиямне уйныйм. «Эх, алмагачларым»да мәктәп директоры Фәридә Раисовна ролен башкарам. Героемда карьерист чалымнары булса да, ул кире образ түгел. Укытучылар өчен тырышып-тырмашып йөрүче хатын. «Күрәсем килгән иде» спектакле куелышы ягыннан иң авыр чыкканы булгандыр. Ул вакытта безгә сәхнәдә «прогон» ясарга вакыт җитмәде. Төп рольне башкарган Рөстәм Гайзуллин, премьерага өч көн кала, ангина белән авырып китте. Ләкин ул барыбер уңышлы килеп чыкты.

**– Әниегез пьесалар да иҗат итә. Аның сезне күздә тотып язылган спектакльләре бармы?**

– «Син бит минем бер генәм», «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» әсәрләрендәге геройлары миңа атап язылган. Беренчесендәге Алинә роле авыр бирелде, чөнки беркайчан да аның хәлендә калганым юк. Сөйгән егетенең Чечня сугышында һәлак булуы турында хәбәр килә. Мин бу халәткә ничек кереп була икән дип азапландым.

Узган җәйдә «Күрәсем килгән иде» һәм «Мәхәббәт чишмәсе» белән Абхазиягә барырга туры килде. Күп кеше спектакльне тәрҗемә белән генә тыңласа да, ахырдан яныбызга килеп рәхмәтләр әйттеләр. Бик ошаттылар.

**– Кечкенәдән, актер булам дип хыялланып, сәхнә артында үстегезме?**

– Сәхнә артында күбрәк Ләйсән булды. Олы кыз буларак, мин дүрт яшькә кадәр әнинең әнисе Мәрвия дәү әнием тәрбиясендә идем. Күчмә театр булгач, әниләр һәрчак гастрольләрдә булды. Мәктәпне тәмамлагач йә укытучы, йә хисапчы, йә актриса буласы идем. Артист тормышының бөтен кыенлыкларын күргән әни: «Без күп азапландык, 12 айның тугызы гастрольләрдә узды. Гаиләң дә булмас. Бөтен кеше дә хатыннарының артист булуын теләми», – дип, артист булу ниятемнән кире күндерде. Шуңа да 10нчы сыйныфны тәмамлагач, Казан дәүләт университетының физика факультетына укырга кердем. Артист буласым язмышыма язылгандыр инде, чөнки дүрт ел укыганнан соң университетны ташлап, театр училищесына киттем. Минем яктан бу бәлки җүләрлек тә булгандыр. Әни: «Синең артыңнан йөрмим, имтиханнарыңа үзең әзерлән. Исламия үзенең кызын төртеп керткән икән, дип килеп әйтүче булмасын», – дип кисәтте. Ул вакытта Илдар абый Хәйруллин икенче курсларны укыта иде, мине үз укучылары янына алды. Аңа чиксез рәхмәтлемен.

**– Училищеда сез булачак ирегез Ренат Шәмсетдиновны да очратасыз.**

– Әйе, без төркемдәшләр идек. Бер күрүдә гашыйк булдым дип әйтә алмыйм, чөнки ул миннән яшьрәк. Башта дуслык булды, ул мәхәббәткә әверелде. Укып бетереп ел ярым узгач өйләнештек. 9 мартта безнең Тинчурин театрына эшкә керүебезгә 26 ел була.

**– Әти-әни юлыннан китүе кыен булдымы?**

– Династия булгач, бездән бик күпне өмет иттеләр. Хәзер дә спектакльдән чыккач, әнигә: «Исламия апа, кызларыгыз, кияүләрегез өчен рәхмәт!» – дип килеп әйтәләр. Шундый сүзләр ишетерлек булгач, димәк, без дөрес юлда.

**– Хыялыгызда уйналмаган нинди рольләр бар?**

– Яшьрәк чакта, менә шушы рольне уйнасам иде, дип йөрисең. Безнең театрда минем яшьтәге хатын-кызлар күп, шуңа да сайланып утырмыйм, кайсы рольне бирсәләр шуңа ябышып, рәхәтләнеп эшлим. «Сүнгән йолдызлар»да мин башта кызлар булып уйнап йөргән идем. 2013 елда режиссерыбыз Резедә Гарипова Гөлнур әби ролен бирде. Кайбер кешеләр яшьләрдән картларга күчүне авыр кичерә. Аңа әзер булмасам да, режиссер «әби итте», дип үпкәләп ятып булмый. Режиссер шулай күрә икән, артист кеше аны башкарып чыгарга тиеш.

**– Үз гаиләгездә театраль династияне дәвам итүче бармы? Улыгыз артист булам димиме?**

– Сәләте юк түгел, ләкин иҗат юлыннан китмәде. КХТИда программист һөнәрен үзләштерә. Аның актер булу теләге бар иде, ләкин мин аңа: «Артист – режиссерга, рольгә бәйле кеше», – дидем. Ришат барыбер иҗат белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта япон мультфильмнарын тавышландыра.

**– Артист кешене бәйле дисез, ләкин сез үзегез дә роль биргәннәрен генә көтеп тора торганнардан түгел. «Уеннан уймак» дигән ике телевизион спектакль төшердегез.**

– Анысы Ләйсәннең хыялы иде. Без бит династия, Мәхмүтовлар. Театр сәхнәсендә бөтен гаиләбез белән бер спектакльдә уйнаганыбыз булмады. Аның бишебезне дә бер проектта күрәсе килде. Төннәр утырып, сценарийлар яздык. Ренат текстны татарчалаштырды. Без бит рус мәктәбендә укыдык, ул татар телен безгә караганда яхшырак белә. Әбиләр монологын әни язды. Хәзер, ярый әле телеспектакльне төшереп калдык, дибез. Съемкалардан соң озак та үтмәде, Роза апабыз (Хәбибрахманова) үлеп китте. Әтинең дә соңгы роле шул булды. Башта берне генә төшерәсе идек, ләкин халык дәвамын сорый башлады. Беренчесен экранлаштырырга режиссер Нурания Җамали ярдәм иткән иде, икенчесенә Ләйсән үзе тырышты. Хәзер өченче сериясен сорыйлар, тик без башка фильм булыр дип торабыз.

**– Көчле хатын-кыз булуы җиңелме?**

– Безнең, гомумән, нәсел шундый. Әни дә, Ләйсән дә, мин дә кыр кәҗәләре кебек әйдәп баручылар. Йомшак буласы килә, әлбәттә. Ренат миңа ияләшкән инде. Ул артист кешенең тынгысыз булырга тиеш икәнен белә. Гаиләдә муен булырга тырышам. Ренат, шаяртып: «Син, хатын, баш булмасаң да, муенны әйбәт борасың», – ди. Бер эштән дә читенсенмим. Әнинең Вишневка бистәсендә йорты бар, анда кирәк икән цементын да әйләндерәм, заливкасын да ясыйбыз, тактасын да тотып торам, кадагын да табып бирәм.

**– Һәр хатын-кыз артист булырга тиеш, диләр. Тормышта рольгә еш керергә туры киләме?**

– Ирең әзрәк кәҗәләнеп алса туры килә. *(Көлә.)* Тормышта без гади кешеләр, алай уйнап йөргән юк. Беркайчан да мин Исламия белән Хәлил кызы дип йөрмәдем. Үземнең Лилия Мәхмүтова буларак танылысым килде.

**– Тормышыгыздан тамашачылар белмәгән берничә факт?**

– Беркайчан да фитнес белән шөгыльләнгәнем булмады. Күптән түгел үземә тренажер алдым. Хәзер бит скандинавия йөреше популяр. Спектакльләрем аз булган көнне спорт белән шөгыльләнәм. Бакчада казынырга яратам. Дүрт сотый җиребез бар, җәем шунда үтә. Помидорын да, кишер, суган, бәрәңгесен, җиләк-җимешен дә утыртам. Бакчабызны бик яратам. Әни күбрәк чәчәкләр үстерә. «Ой, минем розаларым», – дип, һәр чәчәген үбеп йөри. Мин ашый торган әйбер утыртам. Ә иң яраткан чәчәгем – пионнар.

**– Киләчәкне белергә мөмкинлегегез булса, нәрсә турында белергә теләр идегез?**

– Киләчәгемне беләсем килми – куркам. Бүгенге көн белән генә яшим. Элек берәр елга планнар төзи идем. Әтигә спектакльдә инсульт булгач, ярты ел түгел, бер ай да түгел, хәтта иртәгесе көнгә дә планнар кормыйм. Бердәнбер үкенечем бар – гел роль булыр дип хыялланып йөреп, тагын бер бала алып кайтмадым. Ә калганы ничек бар, шулай барсын.

# Тукай бакчасы

КАЗАН БУЙЛАП

**Габдулла Тукай – татар халкының алгарышына, мәдәниятенә, әдәбиятына гаять зур тәэсир иткән, милләтне бөтен дөньяга таныткан шәхес. Аның исемен мәңгеләштерү уңаеннан төрле оешмаларга, урамнарга, мәйданнарга Тукай исемен бирү күркәм күренеш. Тукай исеме белән Дәүләт бүләгенең атау, аңа күп җирләрдә һәйкәлләр куелу да моңа дәлил. Башкалабыз Казанда да бөек шагыйребез исемен йөрткән музей, филармония, урам, бакча бар.**

Казандагы Тукай бакчасы артык зур түгел, җыйнак кына. Ул шәһәребезнең Островский һәм Сәлимҗанов урамнары арасында урнашкан. Шәһәр үзәгендә дисәң дә ялгыш булмас. Шуңа күрә монда һәрчак халык күп була.

Бакчада каен, тирәк, чыршы, ак чыршы, миләш, карагай, туя, юкә агачлары үсә. Куаклар да җитәрлек. Ял итүчеләр өчен заманча итеп эшләнгән эскәмияләр куелган. Бакчаның уртасында 10 м биеклектә Тукай һәйкәле тора. Ул бронза һәм граниттан эшләнгән. (Скульпторлар С.Ахун, Л. Кербель, Л. Писаревский, архитектор Л.Павлов.) Шагыйрьнең сыны – 4,4 м, аннары ул сигез кырлы һәм дүрт кырлы гранит белән тәмамлана. Алар арасы татар милли бизәге белән әйләндереп алынган. Алгы якта гарәп имлясында шагыйрьнең исеме, яшәгән еллары язылган.

Бакчага әлеге һәйкәл 1958 елда урнаштырыла. Шул вакыттан бирле бакча Тукай исемен йөртә башлый. Яздан алып көзгә кадәр һәйкәл тирәли чәчәкләр үсеп утыра. Һәйкәлдән чәчәк бәйләмнәре дә өзелми.

Һәр елны бөек шагыйрьнең туган көне – 26 апрельдә җәмәгатьчелек һәйкәлгә чәчәкләр сала. Тукай бакчасы белән янәшә – Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры мәйданы. Анда шагыйрьнең Шүрәлесенә, Былтырына тап буласың.

Кешеләрне дуслаштыра, берләштерә, таныштыра да әле ул Тукай бакчасы! Кичен яшьләр бакчада очраша, өлкәннәр саф һава сулап йөри, кемнәрдер эскәмиядә китап укып утыра, имтиханнарга әзерләнә. Анда булган һәркемгә бакча уңай тәэсир итә, бәлки Тукай исемен йөрткәнгәдер дә әле бу?

**Нияз БИШБАЛТА,**
Казан.

# «Кытайга да ярдәмебез тиде, Урсайга да...»

ХӘТЕР-ХАТИРӘ

**Рафак абый Дәүләтшин – сугыш чоры баласы. Тугызынчы дистәнең уртасын үткән мөхтәрәм зат. Күпне күргән. Чын тарихны әнә шундый кешеләрдән ишетү рәхәт.**

Рафак Дәүләтшин (сулда) һәм журналист Ибраһим Вәлиев (1959 ел).

Шәмсениса апа һәм Зиннәт абзый Дәүләтшиннар исән чакта, аларның авылы Сарлыда дүрт ел укытучы булып эшләргә туры килде миңа. Ун балалы гаилә. Ветеринария институтын тәмамлаган төпчек уллары Алик (соңрак ул Татарстанның атказанган зоотехнигы булды) яннарында, калганнары үз ояларын корып таралышканнар иде инде. Аликның абыйларының берсе – Вил күрше Вахитов исемендәге совхозда сарык асрау буенча илгә танылган «Руно» берләшмәсендә хезмәт куйды. Анысы исә Татарстанның атказанган ветеринария табибы булды. Ә кыз туганнарының берсе – Татарстанның атказанган укытучысы Лимуза Шәяхмәтова белән Азнакайның һөнәр училищесында бергә эшләдек. Тәвәккәл, бик тырыш, булдыклы нәсел диясем килә.

Сүз башым әлеге нәселдән булган Рафак абый турында иде бит. Сугыш беткән елны авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлый ул. Колхозда үзен яхшы яктан күрсәткән егетне район үзәге Мөслимгә кыска сроклы хисапчылар курсына җибәрәләр. 1946 ел башында әйләнеп кайтуга, Зур Сукаеш авыл советына караган «Каенлы күл» колхозына (авыл исеме дә шулай атала, 1960 елларда юкка чыккан) эшкә билгелиләр. Бераздан Азнакайдагы «Марат» колхозына күчерәләр. Шулай итеп, 16 яшеннән бөтен хезмәт юлын төрле җирләрдә баш хисапчы булып уза.

1950 елның июль аеннан өч ел ярым Рафак абый Кытай Халык Республикасының Порт-Артур шәһәрендә солдат хезмәтендә артиллерист була. Дәүләт югарылыгындагы беренче зур бүләк – «Кытай– Совет дуслыгы» медален дә шунда ала. Шундый ук бүләккә тагын бер якташы – Зур Сукаеш авылы егете, Порт-Артурда диңгез флотында хезмәт итүче Әнис Латыйпов та лаек була. Алар Кытай җирендә ике тапкыр очрашалар. (Әлеге медаль Кытай дәүләте җитәкчелеге тарафыннан сугышчан һәм хезмәт батырлыгы күрсәткән совет кешеләрен бүләкләү өчен булдырыла.) Корея сугышына бәйле рәвештә КХРда хәрби хезмәт үтеп кайткан Рафак Дәүләтшин да, Әнис Латыйпов та, ни сәбәпледер, сугыш ветераннары дип саналмыйлар. Андыйларның саны ил буенча меңнәрчә булырга тиеш. Бу вакыйгаларга һәм анда катнашканнарга карата лаеклы бәя бирәсе иде.

Армиядән кайту белән, Рафак белем күтәрү хәстәренә керешә – Саба районындагы хисапчылар әзерләү училищесына бара. Соңрак, читтән торып, Башкортстанның Юматово финанс техникумын тәмамлый. Авыл хуҗалыгын аякка бастыру төгәл исәп-хисап эшеннән башка мөмкин эшме? Рафак кебек белгеч кадрлар җитми, шуңа күрә дә аны төрле якка тарткалый башлыйлар. Райбашкарма комитеты аны Күктәкә авылындагы «Коминтерн» колхозына баш хисапчы итеп җибәрә, шул авылга якын булган Ык елгасы аша төзелгән кечкенә гидроэлектростанция бухгалтериясе дә аңа йөкләнә. 1956 елда зур авыл саналган Урсайга – Тельман исемендәге колхозга баш хисапчы итеп җибәрелгәч, бер көн монда, бер көн тегендә ат җигеп йөреп эшләргә туры килә. Урсайда тал чыбыгыннан каз оялары үрү остасы Мирсәяф Хәлиуллин заманы өчен бик ыспай гына тарантас та ясап бирә. Дәүләтшиннар гаиләсе бу авылда 11 ел яши һәм эшли. Рафак абыйның җәмәгате – югары белемле татар теле укытучысы, Түбән Сукаеш авылы кызы Мәдинә апа, авылга килгәнче, роно инспекторы булып эшли. Туган авылым Урсайда аларны әле булса онытмыйлар.

Әнис Латыйпов (1970 еллар).

Урсай авылында ике катлы клуб, таштан терлекчелек биналары шул елларда төзелә. Хезмәт Кызыл байрагы орденлы колхоз рәисе, сугыш ветераны Мират ага Гыйләҗетдинов ышанычлы баш хисапчыны җибәрергә теләмәсә дә, Рафак Дәүләтшинны 1967 елда район үзәгендә яңа оештырылган колхозара төзү оешмасына эшкә күчерәләр. Анда ул пенсиягә чykканчы эшли. Татарстанның атказанган икътисадчысы исеменә лаек була. Гомер юлының иң истә калган еллары турында сорагангда, Кытайга да ярдәмебез тиде, Урсайга да, дип искә ала ветеран. Ул бу сүзләрне хәрби хезмәттән соң агроном белгечлеге алган, КПСС Үзәк комитеты каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлаган дусты, Азнакай районы колхоз-совхозларында җитәкче постларда эшләп абруй казанган Әнис Латыйповны да күздә тотып әйтә.

Авыл хуҗалыгын үстерүдә үзеннән лаеклы өлеш керткән Әнис ага Латыйповның да хезмәт биографиясендә төп урынны Урсай авылының Тельман исемендәге колхозында партоешма секретаре һәм хуҗалык рәисе вазифаларын башкаруы тора. Ул биргә гаиләсе белән Рафак абыйлардан соң килә, җәмәгате Даимә апа мәктәптә завуч була. Әнис абый авылны кадрлар белән ныгыту, моның өчен аларга шартлар тудыруга, колхоз хисабына йортлар төзүгә нык игътибар бирә. Бүгенге көндә дә Урсай авылына килеп кергәндә ике дистәгә якын кирпеч йортлардан гына торган төз, матур Төзүчеләр урамы каршылый икән, бу – мәрхүм Әнис Мәгъсүм улының хезмәте.

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,**
хезмәт ветераны.
Азнакай.

# Глаукома белән озак еллар яшәргә була

**Кичә Бөтендөнья глаукомага каршы көрәш көне уңаеннан, «Татар-информ» агентлыгында күз авырулары турында сөйләштеләр. Республиканың баш офтальмологы Айдар Әмиров әйтүенчә,Татарстанда глаукома авырулы 28 мең кеше теркәлгән.**

– Әлеге авыру сукыраюга китерсә дә, кешеләр аны җитди кабул итми. Глаукоманың килеп чыгуы, таралуы әлегә кадәр тулысынча ачыкланмаган. Бу авыру белән күбесенчә 45 яшьтән узган югары кан басымы булган хатын-кызлар интегә. Шулай ук нәселдән килүе дә ихтимал, – диде Айдар Әмиров.

Глаукоманы кисәтү чаралары юк. Әмма табиб кушканнарны үтәсәң, авырган кеше дә озак еллар яши, күрә алачак.

Авыруны гадәттә, катлаулылыгына карап, күзгә махсус тамчылар тамызып яки лазер һәм хирургия юлы белән дәвалыйлар.

Авыру турында халыкка күбрәк мәгълүмат җиткерү өчен, Республика клиник офтальмология хастаханәсендә махсус мәктәпләр дә оештырыла башлаган. Мәктәптә укулар бушлай. Анда табиблар пациентларга авыру, аны дәвалау турында мәгълүмат бирә. Килгән кешеләрнең күздәге кан басымын үлчиләр, күзгә дөрес итеп дару тамчылары тамызырга өйрәтәләр, кызыксындырган сорауларга җавап бирәләр.

**ГЛАУКОМА АВЫРУЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ БИЛГЕЛӘРЕ КҮЗӘТЕЛГӘНДӘ КИҢӘШЛӘР**

- Күз табибына ешрак күренергә;
- күздәге кан басымын нормада тотарга;
- күз белән бәйле авырулар булганда, табиб кушканнарны үтәргә;
- дәвалауны мөмкин кадәр иртәрәк башларга.

– Бу мәктәп кирәкле. Күп нәрсә пациентның табиб кушканнарны төгәл үтәвенә бәйле. Лекцияләр тыңлаган кешеләр күз авыруларына карата игътибарлырак була башлый, – ди Республика клиник офтальмология хастаханәсенең глаукома кабинеты мөдире Ольга Зверева.

**Буада 12 марттан 23енә кадәр Идел буе һәм Урал театрларының I Халыкара фестивале үткәрелә. 12 көн дәвамында буалылар һәм кунаклар 13 драма, бер балалар һәм дүрт курчак театры спектаклен күрә алачак. Фестиваль Мәдәният министрлыгы, Татарстан театр әһелләре берлеге тарафыннан яклау тапты. Әлеге чарага Татарстаннан тыш, Башкортстан, Казахстан, Калмыкия, Коми, Удмуртия, Мари Эл республикалары, Ульяновск театрлары киләчәк.**

# Буага Идел-Урал театрлары җыела

– Без, бу фестивальне оештырып, зур адым ясарга уйлыйбыз. Аны уздыру өчен бөтен шартлар бар. Фестиваль спектакльләре өч мәйданда күрсәтеләчәк. Район җитәкчелеге дә ярдәм итә, – диде фестивальнең директоры Раил Садриев.

– Коллектив әзер. Хәзер тамашачыны әзерләргә кирәк. Россиядә бөтен милли театрларны берләштергән фестиваль юк. Без Россиядәге милли театрлар географиясен җәелдерәчәкбез. Россиянең танылган тәнкыйтьчеләре килүе көтелә. Һәр театр үз репертуарыннан мавыктыргыч спектакль алып килергә тиеш. Бу безнең республика өчен дә зур вакыйга, – ди Камал театрының сәнгать белгече Нияз Игъламов.

Буа муниципаль районы башкарма комитеты урынбасары Лилия Садретдинова әйтүенчә, мондый фестивальнең Буада узуы зур горурлык.

– Моңа кадәр дә бездә театрлар фестивале узды. Районыбызда балалар кече яшьтән үк театрга тартылалар. Әбу фестивальне күрше районнардан да килеп карарга тиешләр. Билет бәяләре 100 сумнан башлана. Әлеге фестиваль туризмны үстерү максатын да күздә тота. Иң мөһиме – буалыларга төрле халыкларның театрлары белән танышырга мөмкин булачак. Фестиваль рус һәм татар телләрендә уза. Спектакльләрдә Идел буе, Урал халыкларының гореф-гадәтләрен, көнкүрешен күрергә мөмкин булачак, – диде Лилия ханым.

**Люция ХӘБИБУЛЛИНА.**

# Актанышка Анатолий Карпов килгән

**Шахмат буенча уникенче дөнья чемпионы булып танылган бөек шәхес Актаныш районына Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов һәм «БлагоДарение» фонды президенты Фәрит Салихов чакыруы буенча килгән.**

Шахмат дөньясының легендасын күрергә дип күп кенә шахмат яратучылар, уен белән кызыксынучылар, катнашучыларның әти-әниләре, туганнары җыелды. «Агыйдел» ансамбленең матур чыгышыннан соң Анатолий Карпов белән әңгәмә булды, теләгән һәр кеше үзен кызыксындырган сорауларны бирә алды. Анатолий Карпов бер уен сеансында сигез кеше белән көч сынашты. Уен бер сәгатьтән артык барды. Кайсыдыр уенчы тиз җиңелде, ә кайберәүләр үзләренең һәр адымын уйлап яхшы чыгыш ясадылар. Ахырдан һәрбер катнашучыга да «Благо-Дарение» хәйрия фонды Анатолий Карповның автографлы китабын бүләк итеп бирде.

# Әрәм булмасын...

## (Уңган хатын монологы)

Хатын-кызның шул инде аның, тиенен-тиенгә санап, бернәрсәне әрәм-шәрәм итмәскә дип тырышып яшәве. Мин дә искәрмә түгел бу яктан. Шулай беркөнне кичке ашка салат ясарга булдым. Дөресрәге, суыткычны ачкан идем, тавык кисәге күзәмә чалынды. Әрәм итеп булмый бит, шуны турап салат ясасам дим. Ананас консервасы да бар. Шуны ачып, ананас кисәкләрен салатка тиз генә турап салдым. Тик менә аның суын кая куярга, әрәм итеп түгеп булмый бит инде. Әчәсе дә килми. Шунда хәтеремә кекс пешерү рецепты килеп төште. Аз гына тырышсам, кичке чәйгә тәмле кекс та буласы икән. Ләкин нишләптер йомырканың сарысын гына салырга кушылган. Агын кая куярга? Суыткычка тыксаң, кибеп әрәм булачак. Хәзер әрәм-шәрәм итә торган заманмы? Кризис. Безе ясарга булдым. Аңа лимон кабыгы уып салдым. Кабыксыз лимоным өстәл өстендә «әрәм булам» дигәндәй, мескен кыяфәттә күзгә карап ята башлады. Ничек ташлыйсың инде аны? Салатка турап салдым. Аңа суган да тиеш әле. Суганнар шалкан кадәр зур. Яртысын гына турадым. Тагын яртысы әрәм була бит инде. Тукта, балалар макарон дип үлеп китә, соус белән тагын да тәмлерәк була бит ул, ясап куйыйм әле, дип, табага ярты суганны турап салдым, өстенә томат пастасы ачып агыздым. Тагын яртысы банкада калды. Юк әрәм итәргә һич кенә дә ярамый. Борщ пешерергә уйладым. Уйлавын уйладым, ләкин өйдә кәбестә юк икән. Киттем кибеткә. Аннан кәбестә, кишер, кер юа торган порошок, тозлы балык, колбаса, салфеткалар һәм дә башмаклар күтәреп кайттым. Соңгылары акциягә иде. Алдым. Кирәге чыкмый калмас. Юл уңаеннан банкка кереп, кредит түләдем. Балалар авылда җәйге ялда төшкән фотоларын ясатырга биргәннәр иде, аларны да алып чыктым. Үкчәсе купкан туфлиемне төзәтергә биргән идем, юл уңаенда аны да әлэктердем. Ипи кибетенә кереп, иртәнге чәйгә дип йомшак күмәч сайладым. Гөнаһ шомлыгы, йортта лифт эшләми икән. Алтынчы катка көчкә күтәреп мендем шуларны. Хәл алып торырга вакыт юк. Хәзер кем эштән, кем укудан кайтып, ашарга сораячак. Борщны тиз генә пешереп бетердем. Нәрсә бар берсен дә калдырмыйча салдым бу юлы кәстрүлгә. Әрәм китмәсен дип, тагын нәрсә дә булса ясарга хәл калмаган иде инде. Билем бөгелми, аякларым сизми, кулларым әзелеп төшәрлек булып сызлый. Диванга барып аудым да үземне сүгеп ятам: вәт җүләр, әрәм китмәсен дия-дия никадәр эш эшләдем. Теге ананас суын түккән генә булсам соң...

**Йолдыз ШӘРАПОВА.**

# СӘЛАМӘТЛЕК спартакиадасында

**Сәламәт тәндә – сәламәт акыл. «Казан» халыкара ат-спорт комплексына кышкы спартакиадага җыелган һәркем өчен бу сүзләр шигарь булып яңгырагандыр. Биредә «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре спорт ярышларында көч сынашты. Чара компаниянең 20 еллыгына багышланган иде.**

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

**Эльвира МОЗАФФАР**

«Татспиртпром» җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары Ринэль Нуретдинов катнашучыларны сәламләгәннән соң, чараның иң кызык өлеше башланды. Сүз уңаеннан, җитәкче үзе дә чаңгы ярышларында катнашты. Бәйрәмгә «Татспиртпром» ширкәтенең барлык филиалларыннан җитәкчеләр, хезмәткәрләр килгән иде. Мамадыш спирт заводы, Чистай, Түбән Кама ликер заводлары, «Татспиртпром» үзәк аппаратының җыелма командасыннан да катнаштылар. Барлыгы 300 кеше.

Любовь Новокупова «Казанский» шәраб җитештерү заводында эшли. 17 ел укытучы, аннары социаль хезмәткәр булып эшләгәннән соң, спирт эчемлекләре җитештерү өлкәсенә килгән. Спартакиадада өстәл теннисы ярышларында катнашты.

– Теннис ракеткасын моннан 30 ел элек кулыма алган идем. Шуннан бирле бу спорт төренә гашыйкмын, – ди ул.

Оля Веселова – Усад спирт заводыннан. Аның өчен бу чара, беренче чиратта – бергә җыелу, очрашып күрешү. Спортта көчеңне сынап карау мөмкинлеге дә.

Спартакиадада тугыз спорт төре буенча көч сынаштылар. Чаңгы ярышлары аеруча күңелле узды. Ир-атлар, хатын-кызлар төрле дистанцияләргә чаптылар. Аннары дүртәр кешедән торган командалар узышты. Һәр филиалдан сайлап алынган лидерлар арасында да чаңгы ярышлары оештырылды. Мини футбол шулай ук бик үзенчәлекле үтте. Ун команданың уенын күзәтү кызык та, мавыктыргыч та иде.

Баш хөкемдар Валерий Кузнецов әйтүенчә, бәйгедә катнашучыларны «Спартак» спорт җәмгыятеннән Татарстан, Россия, халыкара категориядәге тәҗрибәле хөкемдарлар бәяли. «Яшьләрнең берләшүе, спортка тартылулары сөендерә. Бу чараны сәламәтлек спартакиадасы дип әйтер идем», – ди хөкемдар.

– «Татспиртпром» җәмгыятендә җәйге, кышкы спартакиада уздыру матур бер традициягә әйләнде. Беренче чиратта, бу – бергәләп очрашу чарасы, сәламәт тормыш рәвеше алып бару, гаиләләр белән дуслашу, аралашу, күңел ачу мөмкинлеге. Ярыш нәтиҗәләреннән бигрәк, кешенең сәламәт яшәү рәвешенә омтылуы, компаниядәге хезмәткәрләрнең гомуми чараларны хуплап, катнашырга риза булулары мөһим, – ди «Татспиртпром»ның персоналны үстерү буенча директоры Нурия Беломоина.

Сыйфаты, товар ассортименты буенча даны еракларга таралган «Татспиртпром» оешмасы социаль проектларга, спортка зур игътибар бирә. Алар тарафыннан «Казан» халыкара ат-спорт комплексын үстерү буенча күп эш эшләнгән. Биредә көрәш мәйданчыгы һәм футбол кыры булдырылган. «Татспиртпром»ның үзенең җыелма футбол командасы да бар. Хезмәткәрләр атнага ике тапкыр «Манеж» спорт сараенда шөгыльләнә. Әле менә мини футбол буенча «Казан Бизнес Лигасы» корпоратив турнирының язгы уеннарына әзерләнәләр. Нурия Беломоина әйтүенчә, быел волейбол буенча чемпионатка кушылырга исәпләре бар. Һәр филиалда да спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр тудырылган. Хезмәткәрләрнең спортка тартылулары һәрчак хуплана.

Спорт уеннары «Веселые Волгари» эстрада-фольклор ансамбленең чыгышлары белән үрелеп барды. Кунаклар өчен чәй табыны да әзерләнгән иде. Бәйрәмдә коймак белән дә сыйладылар. Хәтта Май чабу бәйрәмендәге сыман, кышкы карачкыны яндыру йоласы да узды.

Кышкы спартакиадада гомуми командалар ярышында Мамадыш спирт заводы директоры Николай Иванов җитәкчелегендәге төркем, уңышлы нәтиҗәләр күрсәтеп, җиңүче дип табылды. Алар акчалата бирелгән премияне спорт өчен кирәк-ярак җиһазлар алуга тотачаклар. Хәер, бәйрәмнән берәү дә буш кул белән китмәде. Һәр төркем, җыелып килгәннәре, спортка битараф булмаганнары өчен, махсус бүләкләнде.

Кышкы бәйрәм тәмамланырга да өлгермәде, спортчылар инде җәйге спартакиада турында уйлый. Июнь аенда узачак спорт бәйрәмендә ярыш төрләре тагын да күбрәк булачак.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) –** «ТАТМЕДИА» АҖ
**«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –**
**БАШ МӨХӘРРИР** ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

**РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ**
Тел: (843) 562-50-12,

**ХАТЛАР БҮЛЕГЕ**
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 684. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

**НӘШРИЯТ**
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

**РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ**
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

**БАСМАХАНӘ**
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы